**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarsta№.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**10.02.2022** **№ 216**

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү һәм Җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләрен карау комиссиясен төзү турында» карары проекты буенча Җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү хакындагы нигезләмәне раслау турында**

«Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган территорияләргә якын урнашкан чикләрне җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 23 декабрендәге 2220 номерлы карары нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында» карары проекты буенча Җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү хакындагы нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

2. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында» карары проекты буенча Җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләрен карау комиссиясен (алга таба - Комиссия) төзергә.

3. Расларга:

3.1. Комиссия турындагы нигезләмәне (2 нче кушымта).

3.2. Комиссия составын (3 нче кушымта).

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарганнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф.Хисамутдинов

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 10.02.2022 №216нче номерлы карары белән расланды

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында» карары проекты буенча Җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү хакындагы**

# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Биектау муниципаль районы территориясендә «Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында» Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының карары проекты буенча Җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү хакындагы нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган территорияләргә якын урнашкан чикләрне җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 23 декабрендәге 2220 номерлы карары нигезендә эшләнде һәм Биектау муниципаль районы территориясендә «Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында» Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының карары проекты буенча җәмәгать фикер алышуларын уздыру процедурасын билгели.

1.2. Әлеге Нигезләмәдә җәмәгать фикер алышулары дигәндә җәмәгать контроле максатларында файдаланыла торган Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында»

карары проекты (алга таба – карар проекты) буенча гавами фикер алышу аңлашыла, түбәндәгеләргә якын урнашкан территорияләрнең чикләрен билгеләү өлешендә:

- мәгариф оешмалары биләвендә һәм (яисә) файдалануындагы биналарга, төзелешләргә, корылмаларга, урыннарга (өстәмә белем бирү оешмаларыннан, өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларыннан тыш);

- балигъ булмаганнарны укыта торган оешмалар кбиләвендә һәм (яисә) файдалануындагы биналарга, төзелешләргә, корылмаларга, урыннарга;

- Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган исемлек буенча медицина эшчәнлеге төрләреннән тыш, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бирелгән лицензия нигезендә төп (устав) эшчәнлеге төре сыйфатында медицина эшчәнлеген яисә төп (устав) эшчәнлеге белән беррәттән, медицина эшчәнлеге төрен гамәлгә ашыручы, оештыру-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның биләвендә һәм (яисә) файдалануында булган биналарга, төзелешләргә, корылмаларга, урыннарга;

- билгеләнгән тәртиптә теркәлгән күчемсез милек һәм хокук объектлары булган спорт корылмаларына;

- күпләп һәм ваклап сату базарларына;

- вокзалларга;

- Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнә торган югары куркыныч чыганаклары урнашкан урыннарга.

1.3. Карар проекты буенча җәмәгать фикер алышуларын оештыручы булып Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тора. Юридик адресы 422700, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл станциясе пос., Кооператив ур., 5й. Электрон почта адресы: Vbiektau.sovet.tatar.ru, телефон номеры 8(84365) 2-30-61 (алга таба - Оештыручы). Җаваплы - компетенциясенә кулланучылар базары һәм хезмәт күрсәтүләр мәсьәләләре кергән Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (М.Р. Булгаков).

Җәмәгать фикер алышуларын уздыруны оештыруны тәэмин итүче вәкаләтле орган булып Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге тора. Электрон почта адресы: Vbiektau.sovet.tatar.ru телефон номеры 8 (84365) 2-30-61 (алга таба – Вәкаләтле орган).

## 2. Җәмәгать фикер алышуларының формасы

2.1. Җәмәгать фикер алышулары Карар проектын Биектау муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча урнаштыру юлы белән уздырыла

2.2. Тәкъдимнәр һәм кисәтүләр Оештыручыга җәмәгать фикер алышуларын үткәрү чорында түбәндәге юллар белән җибәрелә:

- җәмәгать фикер алышуларын Оештыручы исеменә язмача мөрәҗәгать;

- җәмәгать фикер алышуларын Оештыручы адресына почта юлламасы;

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җәмәгать фикер алышуларын Оештыручының электрон почта адресына юллама.

## 3. Җәмәгать фикер алышуларын үткәрү тәртибе

3.1. Иҗтимагый фикер алышулар халык алдында һәм ачыктан-ачык үткәрелә, алар үз теләге белән физик һәм юридик затлар, шулай ук төрле һөнәри һәм социаль төркемнәр вәкилләре, шул исәптән хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләренә Карар проекты кагылган яисә кагылырга мөмкин булган затлар (алга таба - Катнашучылар) катнашында уздырыла.

3.2. Катнашучылар үз фикерләрен ирекле белдерергә һәм Карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы.

3.3. Оештыручы әлеге Нигезләмәнең 2 бүлегенең 2.1 пунктчасында күрсәтелгән мәгълүмати чыганакта, Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә, җәмәгать фикер алышулары башлану турында хәбәр итүне тәэмин итә, ул үз эченә алырга тиеш:

1) Карар проектының исеме;

2) Оештыручының тулы исеме һәм контакт белешмәләре;

3) җәмәгать фикер алышуларын башлап җибәрү һәм төгәлләү сроклары, алар дәвамында Карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул ителә, шулай ук тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү ысуллары турында мәгълүмат;

4) Оештыручының тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул итү өчен җаваплы элемтә затының телефон номеры һәм электрон почтасы адресы;

5) тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү өчен адрес;

6) җәмәгать фикер алышуларын уздыру тәртибе.

3.4. Карар проектына тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәргәндә, Катнашучы турында түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урыны (физик затлар өчен);

2) оешманың тулы исеме, вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме, контакт белешмәләре (юридик затлар, шулай ук һөнәри һәм социаль төркемнәр өчен).

3.5. Җәмәгать фикер алышуларының дәвамлылыгы, Карар проекты “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган көннән алып, 15 календарь көн тәшкил итә.

3.6. Җәмәгать фикер алышуларын уздыру срогыннан соң кергән Карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр исәпкә алынмый.

## 4. Җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләрен билгеләү

4.1. Карар проектына килгән искәрмәләр һәм тәкъдимнәр җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләре буенча йомгаклау документына кертелә. Йомгаклау документы әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендә җәмәгать фикер алышулары беркетмәсе рәвешендә төзелә, ул Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать тукланувы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында» карары проекты буенча җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләрен карау комиссиясенең рәисе, секретаре һәм әгъзалары (алга таба - Комиссия) тарафыннан имзалауның датасын күрсәтеп имзалана.

4.2. Җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләре буенча Комиссия җәмәгать фикер алышуларын уздыру тәмамланган көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча беркетмә әзерли. Җәмәгать фикер алышулары беркетмәсе имзаланган көннән алып 3 эш көненнән дә соңга калмыйча Оештыручыга җибәрелә.

4.3. Җәмәгать фикер алышуларының тәкъдимнәре һәм искәрмәләре тәкъдим итү характерында.

4.4. Җәмәгать фикер алышулары беркетмәсе, җәмәгать фикер алышуларын үткәрү срогы тәмамланганнан соң 15 эш көненнән дә соңга калмыйча, Оештыручы тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarsta.ru/ электрон адрес буенча урнаштырыла.

4.5. Каралган тәкъдимнәр һәм искәрмәләр нәтиҗәләре буенча җәмәгать фикер алышуларын Оештыручы (кирәк булганда) Карар проектын эшләп бетерә һәм имзага Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә җибәрә.

Нигезләмәгә 1 нче кушымта

Җәмәгать фикер алышулары башлану турында хәбәр итү

Җәмәгать фикер алышуларына Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында» карары проекты тәкъдим ителә.

Җәмәгать фикер алышулары «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законнар, Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү мәсьәләләре буенча Җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның _________ _______ номерлы карары нигезендә уздырыла.

Карар проекты буенча җәмәгать фикер алышуларын оештыручы булып Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тора. Юридик адресы 422700, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл станциясе пос., Кооператив ур., 5й. Электрон почта адресы: Vbiektau.sovet.tatar.ru, телефон номеры 8(84365) 2-30-61 (алга таба - Оештыручы). Җаваплы - компетенциясенә кулланучылар базары һәм хезмәт күрсәтүләр мәсьәләләре кергән Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (М.Р. Булгаков).

Карар проекты 20___ елның «___» ________ннән Биектау муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarsta№.ru/ электрон адресы буенча тәкъдим ителде.

Җәмәгать фикер алышуларын уздыру срогы, Карар проекты “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган көннән алып, 15 календарь көн тәшкил итә.

Җәмәгать фикер алышуларын уздыру чорында җәмәгать фикер алышуларында Катнашучылар Карар проекты буенча үз тәкъдимнәрен һәм кисәтүләрен түбәндәге юллар белән тәкъдим итәргә хокуклы:

- җәмәгать фикер алышуларын Оештыручы исеменә язмача мөрәҗәгать итү;

- җәмәгать фикер алышуларын Оештыручы адресына почта юлламасы;

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җәмәгать фикер алышуларын Оештыручының электрон почта адресына юллама.

Иҗтимагый фикер алышулар үткәрү чорында кергән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җәмәгать фикер алышуы тәмамланган көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча Җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләрен карау комиссиясе тарафыннан каралачак һәм җәмәгать фикер алышуларын үткәрү срогы тәмамланганнан соң 15 эш көненнән дә соңга калмыйча Биектау муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге электрон адрес буенча урнаштырылачак: http://vysokaya-gora.tatarsta№.ru/.

Җәмәгать фикер алышуларын уздыру өчен сораулар исемлеге

| |
|---|
| Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында» карары проекты.<br>Зинһар өчен, әлеге форманы электрон почта аша: ____________адресына, _________________ соңга калмыйча җибәрегез.<br>Акт эшкәртүченең күрсәтелгән сроктан соң аңа җибәрелгән мәгълүматны анализлау мөмкинлеге булмаячак. |

Контакт мәгълүматы:

Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге;
Бүлек башлыгы______________________________________,
Телефон ___________________________.
Электрон почта _____________________

Сораулар:

| |
|---|
| 1. Сезнең карашка, тәкъдим ителә торган җайга салу нинди проблеманы хәл итүгә юнәлтелгән? Әлеге проблема актуаль микән? |
| |
| 2. Сезнең карашка, тәкъдим ителгән норматив-хокукый җайга салу юнәлтелгән максатларына ирешерме? |
| |
| 3. Мәсьәләне хәл итүнең сайлап алынган варианты оптималь вариантмы (шул |

| |
|---|
| исәптән тулаем җәмгыять өчен файда һәм чыгымнар күзлегеннән)? Тәкъдим ителгән җайлаштыру максатларына ирешүнең башка вариантлары бармы? Әгәр әйе икән, шулардан, Сезнең фикерегезчә, азрак чыгымлы һәм/яки нәтиҗәлерәк булганнарын аерып алыгыз? |
| |
| 4. Хокукый җайга салу субъектларының вазыйфалары, җаваплылыгы ни дәрәҗәдә тулы һәм төгәл чагылдырылуын бәяләгез, шулай ук хакимият функцияләре һәм вәкаләтләре ни дәрәҗәдә төгәл һәм ике төрле мәгънәдә булмаганча язылган? Сез тәкъдим ителгән нормалар башка гамәлдәге норматив хокукый актларга туры килми яки каршы килә дип санныйсызмы? Әгәр әйе икән, мондый нормаларны һәм норматив хокукый актларны күрсәтегез. |
| |
| 5. Тәкъдим ителә торган хокукый җайга салу проектында эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген алып баруны нигезсез кыенлаштыручы нигезләмәләр бармы? Күрсәтелгән һәр нигезләмә буенча нигезләүләр языгыз, өстәмә рәвештә билгеләп куегыз:<br>- җайга салу максатлары яисә булган проблема белән мәгънә каршылыгы бармы, яисә нигезләмә җайга салу максатларына ирешүгә ярдәм итми;<br>- техник хаталар бармы;<br>- җайга салу нигезләмәләрен үтәү кирәгеннән артык гамәлләргә китерә яки, киресенчә, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектларының гамәлләрен чикли;<br>- җайга салу нигезләмәләрен үтәү эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген алып баруга җитди куркыныч барлыкка китерәме, дәүләт хакимияте органнарының һәм вазыйфаи затларның нигезсез хокуклары барлыкка килүгә ярдәм итәме, нормаларны сайлап куллану мөмкинлегенә юл куямы;<br>- тармакта урнашкан эш практикасы гореф-гадәтләренә, яки хәзерге вакытта кулланыла торган халыкара практикаларга туры киләме. |
| |
| 6. Яңа җайга салу кабул ителү, юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан өстәмә бурычлар башкару мөмкинлеге булмау, эшкуарлык һәм башка эшчәнлек субъектлары өчен артык административ һәм башка чикләүләр һәм бурычлар барлыкка килү өлешендә, нинди нәтиҗәләргә китерергә мөмкин? Конкрет мисаллар китерегез. |
| |
| 7. Тәкъдим ителә торган җайга салуны керткәндә, барлыкка килә торган эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының мөмкин булган чыгымнарын/югалтылган файдаларны бәяләгез. Күрсәтелгән чыгымнарның кайсыларын артык/файдасыз дип санныйсыз һәм ни өчен? |

8. Сезнең карашка, әлеге норматив акт белән кертелә торган таләпләрнең һәм нормаларның үтәлешен тикшереп тору белән нинди проблемалар һәм кыенлыклар туарга мөмкин? Анда хуҗалык итүче субъектларның хокукларын яклау механизмы каралганмы??

9. Тәкъдим ителә торган җайга салуның үз көченә керүгә күчү чоры таләп ителәме (әгәр әйе булса, аның дәвамлылыгы нинди), яңа җайга салуны кертү сроклары буенча нинди чикләүләрне исәпкә алырга кирәк?

10. Сезнең карашка, затларның аерым төркемнәренә карата җайга салуны кертү буенча нинди чыгарылмалардан файдалану максатка ярашлы булыр, тиешле нигезләрне китерегез.

11. Тикшерелә торган проектның аларга карата мөнәсәбәтләрне ачыкларга кирәк булган конкрет нигезләмәләренә һәм нормаларына кагылышлы аерым сораулар,

12. Сезнең фикерегезчә, җайга салу йогынтысын бәяләү кысаларында исәпкә алу максатка ярашлы башка тәкъдимнәр һәм искәрмәләр

«___» ________, 20____ ел

Нигезләмәгә 2 нче кушымта

Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату
рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында» карары проекты (алга таба – Карар проекты) буенча җәмәгать фикер алышуларының _____ елның ______ ____ номерлы беркетмәсе

1. Карар проекты буенча җәмәгать фикер алышуларын оештыручы булып Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тора. Юридик адресы 422700, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Биектау т/юл станциясе пос., Кооператив ур., 5й. Электрон почта адресы: ______________, телефон номеры _____________ (алга таба - Оештыручы). Җаваплы - компетенциясенә кулланучылар базары һәм хезмәт күрсәтүләр мәсьәләләре кергән Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (М.Р. Булгаков).

Карар проекты 20___ елның «___» ________ннән Биектау муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarsta№.ru/ электрон адресы буенча тәкъдим ителде.

2. Җәмәгать фикер алышуларын уздыру срогы, Карар проекты “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarsta№.ru/ электрон адресы буенча урнаштырылган көннән алып, 15 календарь көн тәшкил итә.

3. Җәмәгать фикер алышулары башлану турында хәбәр итү электрон документ рәвешендә ______ елның «____» __________ "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarsta№.ru/ электрон адрес буенча урнаштырылган.

4. Җәмәгать фикер алышуларын уздыру чорында кергән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр:

| №п/п | Тәкъдим/искәрмә керү датасы | Җәмәгать фикер алышуында катнашучы | Тәкъдим/искәрмәнең эчтәлеге | Карау нәтиҗәсе (Карар проектына кертергә/ кире | Нигезләр |
|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | турында белешмәләр | | кагарга тәкъдим итәргә) | |

Имзалар:

Җәмәгать фикер алышуларын
уздыру комиссиясе рәисе _________________
/Фамилиясе И.А./

Комиссия секретаре _________________
/Фамилиясе И.А./

Комиссия әгъзалары ________________
/Фамилиясе И.А./

2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 10.02.2022 №216нче номерлы карары белән расланды

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында» карары проекты буенча Җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләрен карау комиссиясе хакында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында» карары проекты буенча Җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләрен карау комиссиясе (алга таба - Комиссия) Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында» карары проекты буенча кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне караучы коллегиаль киңәшмә орган булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законнарга, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында» карары проекты буенча Җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү турындагы нигезләмәгә, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Әлеге Нигезләмәнең гамәли көче җәмәгать фикер алышуларында Катнашучылардан кергән нәтиҗәләрне, искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне билгеләү өлешендә Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга

якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында» карары проекты (алга таба – Карар проекты) буенча җәмәгать фикер алышуларына кагыла.

4. Комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр:

- Карар проекты буенча кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне карау;

- җәмәгать фикер алышулар беркетмәсен әзерләү һәм җәмәгать фикер алышулар Оештыручысына Биектау муниципаль районы башкарма комитетына (алга таба - Оештыручы) җибәрү.

5. Үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен, комиссия үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләргә хокуклы:

- Оештыручыдан Карар проекты буенча җәмәгать фикер алышулары турында мәгълүмат алырга;

- Оештыручы вәкилен комиссия утырышына чакырырга;

- кергән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне һәрьяклап карарга;

- Карар проектына тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә (кире кагарга) тәкъдим итәргә.

6. Комиссия утырышы, җәмәгать фикер алышуларын үткәрү срогы тәмамланганнан соң, Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында» карары проекты буенча Җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү хакындагы нигезләмәгә туры китереп уздырыла.

7. Комиссия утырышы Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән икесе катнашканда хокуклы була.

8. Комиссия түбәндәге составта төзелә: рәис, рәис урынбасары, Комиссиянең секретаре һәм башка әгъзалары.

Комиссия рәисе булып Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары тора, аның компетенциясенә кулланучылар базары һәм хезмәт күрсәтүләр мәсьәләләре керә.

Комиссия рәисе урынбасары булып Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Әхмәтҗанов Нияз Камил улы тора;

Комиссия секретаре булып Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге баш белгече Гайфуллина Алинә Рафис кызы тора.

Комиссия утырышында Комиссия рәисе чыгыш ясый.

9. Комиссия Карар проектына ачык тавыш бирү юлы белән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә (кире кагарга) тәкъдим итү турында карар кабул итә. Тавышлар тигезләнгән очракта, Комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч була.

10. Комиссия әгъзасы, кабул ителгән карар белән килешмичә, үзенең аерым фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул җәмәгать фикер алышулар беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә кушып бирелергә тиеш.

11. Җәмәгать фикер алышуларын уздыру тәмамланган көннән соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча Комиссия тарафыннан җәмәгать фикер алышулары беркетмәсе рәсмиләштерелә, ул Комиссия рәисе, Комиссия секретаре һәм әгъзалары тарафыннан имзалана.

12. Җәмәгать фикер алышулары беркетмәсе имзаланган көннән алып 3 эш

көненнән дә соңга калмыйча җәмәгать фикер алышуларын Оештыручыга җибәрелә.

Комиссия исеменнән документларны Комиссия рәисе, ул булмаганда - Комиссия рәисе урынбасары имзалый.

13. Комиссияне председатель җитәкли.

14. Комиссия рәисе:

- Комиссия утырышларын үткәрү вакытын һәм урынын билгели;
- Комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;
- Комиссия утырышларында рәислек итә;
- Комиссия әгъзалары арасындагы вазыйфаларны бүлә;
- Комиссия кабул иткән карарларның үтәлешен контрольдә тотуны оештыра;
- документларны, шул исәптән Комиссиянең утырышлар беркетмәләрен имзалый;
- Комиссия утырышларында хәлиткеч тавыш хокукына ия.

15. Комиссия рәисе урынбасары:

- Комиссия карый торган мәсьәләләр буенча материаллар белән таныша;
- Комиссия компетенциясендәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертә;
- Комиссия һәм аның рәисе карарларын үти;
- Комиссия рәисе вазыйфаларын ул булмаган очракта башкара.

16. Комиссия секретаре:

- Комиссия утырышының көн тәртибен әзерли;
- Комиссия карый торган мәсьәләләр буенча мәгълүмат тапшыра;
- җәмәгать фикер алышулары беркетмәсен әзерли һәм Оештыручыга җибәрә.

17. Комиссия әгъзалары:

- Комиссия утырышы көн тәртибенә тәкъдимнәр кертәләр;
- Комиссия карый торган мәсьәләләр буенча материаллар белән танышалар;
- Комиссия компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертәләр;
- Комиссия һәм аның рәисе карарларын үтиләр;
- Комиссия утырышлары беркетмәләрен имзалыйлар.

18. Комиссия кабул иткән карарлар тәкъдим итү характерында булалар.

3 нче кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 10.02.2022 № 216нче номерлы карары белән расланды

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында» карары проекты буенча Җәмәгать фикер алышулары нәтиҗәләрен карауның махсус комиссиясе**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Булгаков Мурад Рамил улы | - Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе |
| Әхмәтҗанов Нияз Камил улы | - Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Гайфуллина Алина Рафис кызы | - Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге баш белгече, комиссия секретаре |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Егорова Марина Ивановна | - Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Казан территориаль органы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Зиатдинов Рамил Равил улы | - «Биектау үзәк хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча) |
| Галимова Раиса Камил кызы | - «Биектау үзәк хастаханәсе» ДАССУ табиб-психиатр-наркологы |
| Латыпов Рөстәм Вагыйзь улы | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Биектау районы буенча бүлегенең полиция (оператив эш буенча) башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Кошелева Саида Мухамедовна | - Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең баш белгече (килешү буенча) |
| Давликамова Алиса Рәсим кызы | - Биектау районы суд приставлары бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Салкова Эльвира Валентиновна | - Татарстан Республикасы буенча Арча, Биектау районнарында Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт идарәсенең территориаль бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Минһаҗев Раил Равил улы | - Биектау муниципаль районы «Административ-техник инспекция» МКУ җитәкчесе |